# КАРАР

**2021 елның 30 ноябре** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Чарлы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 26 ноябрендә 11.00 сәгатьтә һәм 2021 елның 26 ноябрендә 13.00 сәгатьтә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 5 һәм аннан да күбрәк 18 яшькә кадәрге балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Чарлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Чарлы авылының Яшьләр, Богомолов, Казанцев урамнарында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- урамнарны яктырту лампалары сатып алу;
- чишмәне төзекләндерү (материал сатып алу, килешү буенча түләү)
- Чарлы авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча түләү)».

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 201 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 111.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 106 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 5 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлеге Чарлы авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 5 һәм аннан да күбрәк 18 яшькә кадәрге балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Чарлы авыл җирлегенең Чарлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Чарлы авылының Яшьләр, Богомолов, Казанцев урамнарында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- урамнарны яктырту лампалары сатып алу
- чишмәне төзекләндерү (материал сатып алу, килешү буенча түләү)
- Чарлы авылында юлларны кардан чистарту (килешү буенча түләү)»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Чарлы авыл җирлеге башлыгы Э.Н. Козлов